КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1132

Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасының катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасы катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать

комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 20 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин